КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 май г.Казань № 359

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары (учреждениеләре) тарафыннан сатып алына торган азык-төлек товарларына максималь бәяләрне формалаштыру турында» 2017 ел, 25 сентябрь, 715 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль оешмалары (учреждениеләре) тарафыннан сатып алына торган азык-төлек товарларына максималь бәяләрне формалаштыру турында» 2017 ел, 25 сентябрь, 715 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 декабрь, 966 нчы; 2018 ел, 11 апрель, 232 нче; 2018 ел, 21 ноябрь, 1026 нчы; 2019 ел, 28 август, 706 нчы; 2020 ел, 11 май, 376 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Татарстан Республикасының Дәүләт заказы агентлыгы» акционерлык җәмгыятенә азык-төлек товарларына, «Товарлар тасвирнамәләре» мәгълүмат ресурсындагы товарлар тасвирнамәләрен исәпкә алып, Азык-төлек товарлары исемлеге нигезендә идентификация кодларын (алга таба - тикерлар) бирүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.»;

4 пунктта «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт оешмалары (учреждениеләре) тарафыннан сатып алына торган азык-төлек товарларына максималь бәяләр формалаштырганда мәгълүмати хезмәттәшлек регламентында:

1.2 пунктның бишенче абзацын төшереп калдырырга;

2.3 пунктта «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт оешмалары (учреждениеләре) тарафыннан сатып алына торган азык-төлек товарлары исемлегенә түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «$1^1$. | Йодказеин белән баетылган бодай икмәге | Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы,<br>гомуми белем бирү оешмасы,<br>сәламәтлек саклау системасының медицина оешмасы,<br>социаль хезмәт күрсәтү оешмасы,<br>балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру,<br>физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек алып баручы һөнәри белем бирү оешмасы». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин